ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘТНӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ЯҢА ШАШЫ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ

СОВЕТ НОВОШАШИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АТНИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО
РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

422008 Республика Татарстан Атнинский район с. Новые Шаши. Тел. 3-23-23

**КАРАР №64**

Яңа Шашы авылы 9 февраль 2023 ел

**Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы “Яңа Шашы авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә, Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Яңа Шашы авыл җирлеге Советы карар итте:

1. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Яңа Шашы авыл җирлеге Советының 29.03.2011 № 16 карары белән расланган Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районының “Яңа Шашы авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Уставына кушымта нигезендә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертергә (22.03.2012 № 35, 18.09.2012 № 48, 03.12.2012 № 55, 08.10.2013 № 73, 23.03.2015 № 114, 02.05.2016 № 28, 28.08.2017 № 56, 25.04.2018 № 71, 03.10.2019 № 107, 29.01.2021 № 16, 01.09.2021 № 33, 18.07.2022 № 50 үзгәрешләре белән).

2. Әлеге карарны законнарда билгеләнгән тәртиптә дәүләт теркәвенә алу өчен җибәрергә.

3. Әлеге карарны дәүләт теркәвеннән соң Әтнә муниципаль районының www.atnya.tatarstan.ru рәсми сайтында һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге www.pravo.tatarstan.ru Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карар «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында»гы 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 44 статьясындагы 8 өлеше нигезендә үз көченә керә.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам..

Яңа Шашы авыл җирлеге башлыгы Сабирҗанов М.С.

Татарстан Республикасы
Әтнә муниципаль районы Яңа
Шашы авыл җирлеге Советының
09.02.2023 ел № 64 карарына
кушымта

**Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы
"Яңа Шашы авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге
Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр**

1. 19 статьяның 5 пунктын түбәндәге эчтәлекле яңа редакциядә бәян итәргә:

«5. Ачык тыңлауларны үткәрү вакытын һәм урынын күрсәтеп үткәрү турында мәгълүмат, шулай ук халык алдында тыңлауларга чыгарыла торган муниципаль норматив хокукый акт проекты халык алдында тыңлаулар уздыру көненә кадәр 7 эш көненнән дә соңга калмыйча Әтнә муниципаль районының www.atnya.tatarstan.ru рәсми сайтында бастырып чыгарылырга (халыкка җиткерелергә) һәм шулай ук «Дәүләт һәм муниципаль хезмәт күрсәтүләрнең (функцияләрнең) бердәм порталы» федераль дәүләт мәгълүмат системасында урнаштырылырга тиеш";

2. 19 статьяның 6 пунктын түбәндәге эчтәлекле яңа редакциядә бәян итәргә:

«6. Халык алдында тыңлаулар үткәрү һәм муниципаль норматив хокукый акт проекты турында мәгълүмат бастырып чыгарылган (халыкка җиткерелгән) көннән башлап районда яшәүчеләр халык алдында тыңлауларга чыгарылган мәсьәлә яки муниципаль норматив хокукый акт проекты буенча тәкъдимнәр һәм искәрмәләр, шул исәптән «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең (функцияләрнең) Бердәм порталы» федераль дәүләт мәгълүмат системасы аша да җирлек башлыгына җибәрергә хокуклы.

Кисәтүләр һәм тәкъдимнәр җибәрү гавами тыңлаулар уздыру көненә кадәр 2 эш көненнән дә соңга калмыйча тәмамлана.

Җирлек башлыгы керүче тәкъдимнәрне гомумиләштерүне һәм аларны гавами тыңлауларда катнашучыларга җиткерүне оештыра.»;

3. 19 статьяның 9 пунктын түбәндәге эчтәлекле яңа редакциядә бәян итәргә:

«9. Гавами тыңлаулар нәтиҗәләре Әтнә муниципаль районының www.atnya.tatarstan.ru рәсми сайтында һәм «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең (функцияләрнең) бердәм порталы» федераль дәүләт мәгълүмат системасында ачык тыңлаулар уздырылганнан соң 5 эш көненнән дә соңга калмыйча басылып чыгарга (халыкка җиткерелергә) тиеш.»;